МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.05.2024 Казан ш № 394

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның «30» маендагы 394 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гаилә составында, тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, өлкән баласына 18 яшь тулмаган яки, көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада уку шарты белән, 23 яшь тулмаган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 8 декабрендәге 675 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2016 №315, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, от 07.05.2018 №350, от 18.09.2018 №858, от 22.04.2019 №290, 28.08.2019 №655, 07.11.2019 №933, 28.02.2020 №135, 13.07.2020 №499, 09.10.2020 №717, 04.06.2021 №395, 07.09.2021 №640, 15.04.2022 №280, 10.11.2022 № 998, 13.05.2024 №350 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Гаилә составында, тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, өлкән баласына 18 яшь тулмаган яки, көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада уку шарты белән, 23 яшь тулмаган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) субсидия билгеләү турында гариза (алга таба – гариза), банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп:

әлеге Регламентка 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә кәгазь документ формасында;

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);

2) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

3) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

4) чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсен һәм гомуми белем бирү оешмасында белем ала торган 16 яшьтән олырак бала өчен әлеге документның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү оешмасында яки укуны гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы укыту факты турында белешмә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларны тапшыра.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БИАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.»;

2.6.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшәү урыны буенча гариза бирүче белән теркәлгән гражданнар турында» (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан)»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында» (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан)»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

яшәү урыны буенча гариза бирүче белән теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан);

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле органнардан алынган белешмәләр.»;

3.4.2 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшәү урыны буенча гариза бирүче белән теркәлгән гражданнар турында» (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан)»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан);».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331, 06.08.2021 №567, 01.10.2021 №710, 13.04.2022 №273, 18.11.2022 №1030, 23.08.2023 №695, 10.01.2024 №3, 13.05.2024 №350 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентында:

2.6.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча белән тулыландырырга:

«8) һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү оешмасында яки укуны гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге

баланы укыту факты турында белешмә.»;

2.6.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүләр алу турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүләр алу турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак бинага милек хокукы турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – җирле үзидарә органнарыннан;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

инвалидлык билгеләү факты турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан;

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында – җирле үзидарә органнарыннан;

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

салымнар һәм җыемнар буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләнгән очракта) – Федераль салым хезмәтеннән;

мөрәҗәгать итүчедә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы өч елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булуы (булмавы) турында – Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасыннан;

Россия Федерациясенең башка субъектында социаль ярдәм чараларын алу/алмау турында – «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан;

реабилитация турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

паспортның гамәлдә булуы турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

мөрәҗәгать итүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларын алуы турында (мөрәҗәгать итүчеләргә әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән компенсацияне билгеләү өчен) – «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан.

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың гомуми белем бирү оешмасында укуы турында.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларны үз инициативасы буенча бирергә хокуклы.»;

3.4.3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың гомуми белем бирү оешмасында укуы турында.».